| Каралды | Килешенгән | Раслыйм |
|---|---|---|
| Башлангыч сыйныф укытучыларының мәктәп методик берләшмә җитәкчесе | Укыту эшләре буенча директор урынбасары | Мәктәп директоры |
| _________Э.М. Тухбатуллина | __________Г.Т.Исмәгыйлова | ___________Г.Т.Сабирҗанова |
| Беркетмә №_1__ | «28» август 2017 ел | 71нче боерык |
| «26» август 2017 ел. | | «28» август 2017ел |

ТР Сарман муниципаль районы «Сарман гомуми урта белем бирү мәктәбе»

муниципаль белем бирү бюджет учреждениесе

**Әхәтова Илмира Әсбәх кызы,**

башлангыч сыйныф укытучысы

# ТАТАР ТЕЛЕ, 1нче б сыйныфы

Каралды
Мәктәп педагогик советы
утырышы беркетмәсе №1
«28» август 2017 ел

**2016 – 2017 нчы уку елы**

**«Татар теле» фәне эш программасына аннотация**

1нче сыйныф өчен эш программасы база дәрәҗәсендә белем бирү программасына нигезләнеп төзелде. Ул Россия Федерациясенең мәгариф турында Федераль Законы, № 273 – ФЗ, декабрь, 2012; Татарстан Республикасының “Мәгариф турында” гы Законы 22.07.2013 №68; Татарстан Республикасының “Татарстан Республикасының дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасындагы башка телләр турында” гы Законы, № 443 РТ, 18.07. 2004;Татар теленнән гомуми белем бирүнең дәүләт стандартына.- ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, Казан, 2008; Башлангыч гомуми белем бирү программаларына.Татар һәм рус телләре– Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2010.; үстерешле укыту принциплары белән традицион белем бирү принципларының үзара тыгыз бәйләнештә булуын тәэмин итә торган «Перспективалы башлангыч мәктәп» концепциясенә; “Татар телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбендә ана теле укыту: гомуми программа” сына -1 – 4 нче сыйныфлар, Ч. М. Харисова, И. Х. Мияссарова, Ф. Ш. Гарифуллина, Казан , 2011.

Программа елга 68 сәгатькә (атнага 2 сәгать) каралган.

Курсның **максаты** — укучыларны татар теленең график системасы төзелеше һәм функциясенең гомуми закончалыклары белән танышу нигезендә башлангыч уку һәм язуга өйрәтү. Бу үз чиратында укучыларда тел турында белем һәм күнекмәләрнең формалашуына нигез булып тора.

Грамотага өйрәнү чорында график эшчәнлекне үзләштерү — I сыйныф укучысының **төп бурычы**. Чөнки бу эшчәнлек нәтиҗәсендә балаларда уку һәм язу күнекмәләре формалаша.

Грамотага өйрәнү процессында балаларда татар теле системасының төп тел берәмлекләре (аваз, сүз, сүзтезмә, җөмлә, текст) турында күзаллау туа, фонематик ишетү һәм авазны әйтү культурасы үсә. Алар, **беренчедән**, төрле шартлы модельләр (квадрат, түгәрәк) һәм махсус транскрипция билгеләре системасы нигезендә сүзнең аваз формасын күз алдына китереп әйтә алу; **икенчедән,** сөйләмнең фонетик язуын тиешле басма яки язма хәрефләргә күчерү; **өченчедән**, сүзнең хәреф моделе буенча аваз формасын төзү эшчәнлеген, ягъни уку күнекмәләрен үзләштерәләр. Шул ук вакытта укучылар язма хәрефләрне, аларны иҗекләргә, сүзләргә тоташтырып язу технологиясен дә үзләштерәләр.

«Әлифба» һәм шулай ук «Язу дәфтәре»ндә аваз һәм хәрефләрне өйрәнү эзлеклелеге татар графикасының позицион (иҗек) принцибына нигезләнгән.

Сузык авазлар һәм аларга билге булып килгән хәрефләр беренче чиратта өйрәнелә, чөнки алар иҗек төзи, шуның нигезендә укучылар уку технологиясе белән таныша.

Сузыклардан соң сонор тартыклар өйрәнелә. Бу аларның яңгырау һәм саңгырау парларының булмавы, яңгырашы ягыннан сузык авазларга якын торуына бәйле. Нәкъ менә шушы тартык аваз төркемнәре аша графиканың позицион принцибы төшенчәсе кертелә, ә бу үз чиратында хәрефнең үзенчәлеген янындагы хәрефләр йогынтысында гына белергә мөмкинлекне аңлата

**Татар теле буенча**
**укыту-тематик планлаштыру**

**Сыйныф** - 1.

**Сәгатьләр саны**: барлыгы – 66 сәгать; атнага – 2 сәгать.

Эш программасы Россия Федерациясенең мәгариф турында Федераль Законы, № 273 – ФЗ, декабрь, 2012; Татарстан Республикасының “Мәгариф турында” гы Законы 22.07.2013 № 68; Татарстан Республикасының “Татарстан Республикасының дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасындагы башка телләр турында” гы Законы, № 443 РТ, 18.07. 2004; Татар теленнән гомуми белем бирүнең дәүләт стандартына.- ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, Казан, 2008; Башлангыч гомуми белем бирү программаларына.Татар һәм рус телләре– Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2010.; үстерешле укыту принциплары белән традицион белем бирү принципларының үзара тыгыз бәйләнештә булуын тәэмин итә торган «Перспективалы башлангыч мәктәп» концепциясенә; “Татар телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбендә ана теле укыту: гомуми программа” сына -1 – 4 нче сыйныфлар, Ч. М. Харисова, И. Х. Мияссарова, Ф. Ш. Гарифуллина, Казан , 2011; «Сарман гомуми урта белем бирү мәктәбе» муниципаль белем бирү бюджет учреждениесенең 2017-2018 нчы уку елына укыту планына нигезләнеп эшләнде.

## Аңлатма язуы

Эш программасы Россия Федерациясенең мәгариф турында Федераль Законы, № 273 – ФЗ, декабрь, 2012; Татарстан Республикасының "Мәгариф турында" гы Законы 22.07.2013 №68; Татарстан Республикасының "Татарстан Республикасының дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасындагы башка телләр турында" гы Законы, № 443 РТ, 18.07. 2004;Татар теленнән гомуми белем бирүнең дәүләт стандартына.- ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, Казан, 2008; Башлангыч гомуми белем бирү программаларына.Татар һәм рус телләре– Казан: "Мәгариф" нәшрияты, 2010.; үстерешле укыту принциплары белән традицион белем бирү принципларының үзара тыгыз бәйләнештә булуын тәэмин итә торган «Перспективалы башлангыч мәктәп» концепциясенә; "Татар телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбендә ана теле укыту: гомуми программа" сына -1 – 4 нче сыйныфлар, Ч. М. Харисова, И. Х. Мияссарова, Ф. Ш. Гарифуллина, Казан , 2011; «Сарман гомуми урта белем бирү мәктәбе» муниципаль белем бирү бюджет учреждениесенең 2017-2018 нчы уку елына укыту планына нигезләнеп эшләнде.

**Барысы** – 66 сәгать.

**Атнага –** 2 сәгать.

Программа үтәлү өчен түбәндәге **укыту-методик әсбаплар** кулланыла:

- Ф.Ш.Гарифуллина, И.Х.Мияссарова, Р.Р.Шәмсетдинова.Әлифба. 1 нче сыйныф: Дәреслек.- Казан: «Мәгариф-вакыт"нәшрияты, 2011.

-И.Х.Мияссарова,Ч.М.Харисова. Татар теле. 1 нче сыйныф: Дәреслек .-Казан «Мәгариф-вакыт"нәшрияты, 2011 .

-И.Х.Мияссарова,Ч.М.Харисова. Татар теле. 1 нче сыйныф: Методик кулланма.-Казан «Мәгариф-вакыт"нәшрияты, 2011

Беренче сыйныфта татар телен өйрәнү "**Грамотага өйрәнү" курсы** белән башлана. Грамотага өйрәнү **өч этаптан** тора: **әзерлек, төп (аваз-хәреф) һәм йомгаклау этаплары**. "Грамотага өйрәнү" курсыннан соң татар теле һәм әдәби уку фәннәре аерым өйрәнелә башлый.

Курсның **максаты** — укучыларны татар теленең график системасы төзелеше һәм функциясенең гомуми закончалыклары белән танышу нигезендә башлангыч уку һәм язуга өйрәтү. Бу үз чиратында укучыларда тел турында белем һәм күнекмәләрнең формалашуына нигез булып тора.

Грамотага өйрәнү чорында график эшчәнлекне үзләштерү — I сыйныф укучысының **төп бурычы**. Чөнки бу эшчәнлек нәтиҗәсендә балаларда уку һәм язу күнекмәләре формалаша.

Грамотага өйрәнү процессында балаларда татар теле системасының төп тел берәмлекләре (аваз, сүз, сүзтезмә, җөмлә, текст) турында күзаллау туа, фонематик ишетү һәм авазны әйтү культурасы үсә. Алар, **беренчедән**, төрле шартлы модельләр (квадрат, түгәрәк) һәм махсус транскрипция билгеләре системасы нигезендә сүзнең аваз формасын күз алдына китереп әйтә алу; **икенчедән,** сөйләмнең фонетик язуын тиешле басма яки язма хәрефләргә күчерү; **өченчедән**, сүзнең хәреф моделе буенча аваз формасын төзү эшчәнлеген, ягъни уку күнекмәләрен үзләштерәләр. Шул ук вакытта укучылар язма хәрефләрне, аларны иҗекләргә, сүзләргә тоташтырып язу технологиясен дә үзләштерәләр.

«Әлифба» һәм шулай ук «Язу дәфтәре»ндә аваз һәм хәрефләрне өйрәнү эзлеклелеге татар графикасының позицион (иҗек) принцибына нигезләнгән.

Сузык авазлар һәм аларга билге булып килгән хәрефләр беренче чиратта өйрәнелә, чөнки алар иҗек төзи, шуның нигезендә укучылар уку технологиясе белән таныша.

Сузыклардан соң сонор тартыклар өйрәнелә. Бу аларның яңгырау һәм саңгырау парларының булмавы, яңгырашы ягыннан сузык авазларга якын торуына бәйле. Нәкъ менә шушы тартык аваз төркемнәре аша графиканың позицион принцибы төшенчәсе кертелә, ә бу үз чиратында хәрефнең үзенчәлеген янындагы хәрефләр йогынтысында гына белергә мөмкинлекне аңлата. Моны алда өйрәнелгән сузык аваз хәрефләре ярдәмендә күрсәтергә мөмкин: а, ы, у, о хәрефләре — тартык авазның калынлыгын; ә, э, и, ү, ө, е хәрефләре нечкәлеген белдерә. Калын сузык аваз хәрефләре янында тартыкларның — калын, нечкә сузык аваз хәрефләре янында нечкә әйтелүен төшендерү аеруча мөһим.

Моннан тыш, кыска [й] авазын өйрәнү е, ю, я хәрефләре ике аваз кушылмасына, ягъни [й] һәм тиешле сузыкка билге булып килүе белән дә танышырга ярдәм итә.

Алга таба тартыкларның яңгырау һәм саңгырау парларын өйрәнгәндә, мисалларга таянып, балалар язуда тартыкларның калынлык һәм нечкәлекләрен белдерү кагыйдәләрен ныгыталар.
Соңыннан алар аеру билгеләре [ь,ъ] булган сүзләргә аваз анализы ясарга һәм ул сүзләрне укырга өйрәнәләр, шуннан соң гына парсыз шаулы тартыклар белән танышалар, аларның язылыш үзенчәлекләрен үзләштерәләр.

I сыйныф укучысы кыска гына вакыт эчендә өйрәнелә торган аваз еш кулланылган сүзләрне, текстларны укырга өйрәнә, нәтиҗәдә хәрефләрне тиешле авазларга күчерә.

«Әлифба»да уку өчен махсус төзелгән текстлардан тыш, балаларның яшь үзенчәлекләренә туры килгән һәм балаларда танып белү эшчәнлеген формалаштырырга ярдәм итә торган башка жанрдагы әсәрләр: шигырь, табышмак, мәкаль, әйтем, тизәйткеч, санамышлар да урын алган. Грамотага өйрәтү дәресләрендә балаларның фонематик ишетеп аңлау һәм аваз культурасы үсешенә сүзләрне «үстерү» һәм сүзләрне үзгәртеп төзү алымнарын куллану нәтиҗәсендә ирешелә. Сүзләрне «үстерү»нең асылы сүзнең авазлар санын акрынлап үстерә баруда, бу башлангыч сүзнең үзгәрүенә һәм яңа сүзләр ясауга китерә. Мәсәлән: бал — бала — балан — баланлы — баланлык**.** Бу дәреслектәге лексик материалны баетып кына калмый, ә укучыларда күзәтүчәнлекне үстерүгә һәм аңлап уку техникасын формалаштыруга җирлек тудыра. Мондый чылбырдагы сүзләрне уку берьюлы ике дәрәҗәдә башкарыла: а) иҗекләп (җырлап, йөзмә, салмак) уку; ә) авазларны дөрес әйтеп (орфоэпик), басымнарны дөрес куеп уку.

Шулай ук сүзләрне үзгәртеп төзү алымы да кулланыла, бу укучыларга сүзгә бер аваз өстәү яки аның бер авазын үзгәртү нәтиҗәсендә сүзнең мәгънәсе тулысынча үзгәрүне күзәтергә мөмкинлек бирә, мәсәлән: көн — төн, бала — балан һ.б.

Бу этапта җиде яшьлек балалар алдында торган **төп бурыч** булып, басма һәм язма хәреф билгеләренең формаларын үзләштерү тора. Басма һәм язма хәрефләр системасына структур-системалы якын килү нәтиҗәсендә, хәрефләрне төзү максатыннан, аларның элемент-өлгеләре эшләнде. Аларны кулланып, укучы үз куллары белән өйрәнелә торган хәреф формасын мөстәкыйль төзи алуга ирешә.

I сыйныфта балалар укырга өйрәнү белән параллель язарга да өйрәнә. Укудан аермалы буларак, язу кул хәрәкәте компоненты булып тора. Язуның график күнекмәләре (хәрефләрнең рәвешләрен, тоташ язу, язу тизлеген үзләштерү) — хәрәкәт күнекмәләренең бер төре. Язу процессында һәр авазның язма хәрефен күңелдә тудырырга, бу очракта шул аваз нинди хәреф билгесе белән белдерелүен искә төшерергә һәм кул чугы мускулларын хәрәкәтләндереп, шул хәрефне дөрес язарга кирәк. Катлаулы кул хәрәкәте эшчәнлеге буларак, язуны автоматлашу дәрәҗәсенә җиткерү нәтиҗәсендә график күнекмә барлыкка килә.

Язарга өйрәтү, уку кебек үк, **өч (әзерлек, төп (аваз-хәреф) һәм йомгаклау) этаптан** тора.

**Әзерлек этабында** I сыйныф укучылары график системаның структур берәмлекләре, яки татар алфавитының язма хәрефләре элементлары белән таныша. Язарга өйрәнүнең **төп этабында** (ул әлифба чорына туры килә) балалар барлык язма хәрефләрне иҗекләрдә, сүзләрдә, җөмләләрдә кушып (тоташ) язу күнекмәләрен алалар.

**Йомгаклау этабында** балаларның язуларындагы график һәм каллиграфик хаталар төзәтелә, график күнекмәләр ныгытыла.

Татар теленнән гомуми башлангыч белем бирүнең **максатлары**:

- татар телендә аралашу күнекмәләре булдыру;
- тел чараларын аралашу эчтәлегеннән чыгып сайлый белергә өйрәтү;
- тел белеменең фонетика, лексика, грамматика бүлекләре буенча башлангыч белем бирү, өйрәнелә торган тел берәмлекләрен тикшерә һәм куллана белү күнекмәләрен булдыру;
- сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләре буенча күнекмәләр формалаштыру;
- укучыларда татар теленә хөрмәт һәм ихтирам тәрбияләү, телнең чисталыгын, дөреслеген саклау. Телне, халыкның рухи мирасын өйрәнүгә кызыксыну уяту.

Тәкъдим ителә торган программада татар теленә өйрәтүнең **бурычлары** түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1. Укучыларда ана телен өйрәнүгә кызыксыну, омтылыш, эзләнергә теләк уяту, үз милләтеңә, телеңә мәхәббәт тәрбияләү кебек уңай сыйфатлар булдыру.
2. Балаларга татар теленең төрле бүлекләре буенча белем бирү:

а) фонетика,лексика грамматикага караган башлангыч мәгълүмат бирү;

ә) телебезнең орфоэпиясе, лексикасы, грамматикасы, пунктуациясе буенча күнекмәләр булдыра башлау. Хәрефләрдән иҗекләр һәм сүзләр, сүзләрдән сүзтезмәләр һәм җөмләләр төзергә өйрәтү.

3. Укучыларны дөрес,матур итеп укырга, укыганның эчтәлеген сөйләргә, аерым темалар буенча әңгәмәләр кора белергә, аралашканда тел чараларыннан урынлы файдаланырга өйрәтү.

4. Телдән һәм язма сөйләм осталыгы һәм күнекмәләре булдыру.

5. Укучыларда татар мәдәниятенә караган мәгълүматлылыкны үстерү.

Балаларны укый –яза белергә өйрәтү ике чорга бүленә:

1) грамотага әзерлек чоры – 4сәг.;

2) әлифба чоры – 38 сәг.;

Грамотага өйрәтү үзара тыгыз бәйләнгән укый һәм яза белергә өйрәтүнең башлангыч процессыннан гыйбәрәт аналитик – синтетик аваз – хәреф методы белән тормышка ашырыла; авазлар һәм хәрефләр, иҗекләр һәм сүзләр, җөмләләр һәм бәйләнешле сөйләм өстендә эшләү күнегүләре аша ныгытыла. Аваз, хәреф — тану берәмлеге, иҗек — уку берәмлеге, сүз — аңлау берәмлеге, җөмлә — мәгълүмат-хәбәрлек берәмлеге (Кош оча. Балык йөзә.) икәнен гамәли аңлап, «чын уку һәм чын язу»ның җөмлә укудан һәм җөмлә язудан башланганын белеп эшләүләренә ирешелә.

***Грамотага әзерлек чоры ике төп максатка*** ия:

- укучыларны гомумән уку процессынаңлап үзләштерүгә һәм аеруча уку техникасына (басма сүзне авазландыра белүгә) хәзерләү;
- язу процессын (сөйләмне язма билгеләр белән күрсәтүне) аңлап үзләштерүгә әзерләү.

***Әлифба чоры түбәндәге максатларга*** ия:

- балаларны укырга һәм язарга өйрәтү;
- дөрес язу күнекмәләрен үзләштерүгә нигез салу;
- элементар орфографик мәгълүматлар бирү;

Дәресләрне оештырганда уен элементлары кергән алымнар куллану отышлы. Интеграл дәресләр уздыру вакытны экономияләргә, дәрестә күп эш башкарыррга мөмкинлек бирә. Әлифба чорында ук укучыларны ишетеп язарга күнектерә башларга кирәк.

**Искәрмә:** «Сарман гомуми урта белем бирү мәктәбе» муниципаль белем бирү бюджет учреждениесенең «Укыту предметы, курсы, дисциплинасының эш программасы турында»гы 2016 нчы елның 29 нче августында педсоветта каралган (беркетмә № 1) һәм мәктәп директоры тарафыннан 2016 нче елның 29 нчы августында чыккан 109 нчы санлы приказы белән расланган нигезнамәсенең 5 пунктына таянып, дәресләр бәйрәм көннәренә туры килгән очракта, программа сәгатьләрне берләштерү исәбенә үтәлә.

**Татар теле фәнен өйрәнгәндә мөһим юнәлешләр**

Һәр теманы өйрәнгәндә түбәндәге мөһим юнәлешләргә басым ясарга:

-патриотик хисләр ( Туган илгә мәхаббәт; туган җиргә, туган халкыңа хезмәт итү);
-кешеләрне хөрмәт итү(тугрылык, намуслылык,шәфкатьлелек);
- гаиләгә ярдәм итү( әти-әнигә хөрмәт, кечкенәләргә ярдәм итү);
- хезмәтне ярату,алга омтылыш булдыру;
- халыкларның культурасын өйрәнү;
- тынычлык өчен көрәшү.

**Татар теле фәнен өйрәнүдән көтелгән нәтиҗәләр**

**Шәхси нәтиҗәләр:**

-укучыларда татар телен өйрәнүгә кызыксыну, омтылыш уяту;
-тел аша әйләнә-тирә тормышка игътибар, дөрес мөнәсәбәт булдыру;
-укучыларның фикерләү сәләтен үстерү;
-баланың үзенә һәм башкаларга бәя бирүенә, үз-үзен тәрбияләвенә ирешү;
-дөрес телдән һәм язма сөйләмгә ия булуның һәр кешенең индивидуаль культура дәрәҗәсенең күрсәткече икәнен аңлату;
- татар сөйләм әдәбенә хас булган сүзләрне дөрес куллану (танышканда, саубуллашканда, табын артында утырганда, рәхмәт әйткәндә, мөрәҗәгать иткәндә, гафу үтенгәндә, тәбрикләгәндә һ..б. очракларда).

**Предмет** нәтиҗәләр:

-татар теленең әдәби нормалары турында беренчел күзаллау булдыру;
-өйрәнгән кагыйдәләрне куллана белү;

-язганны тикшерә белү;
-аваз, иҗек, сүз, сүз төркеме, җөмлә, җөмлә кисәкләре кебек тел берәмлекләрен таба, аера, чагыштыра, төркемнәргә аера , характеристика бирә белү;

**Танып белү УУГ:**

**Укучылар өйрәнәчәк:**

-белемнәр системасында ориентлашырга (яңа белемне алдан өйрәнгән белемнән аеру);
-информация чыганакларын сайлап алырга (китапта ориентлашырга);
-яңа белемнәр табарга: китапны, тормыш тәҗрибәсен, дәрестә алган информацияне, белешмәлекне кулланып сорауларга җавап табарга;
-алган информацияне эшкәртергә: нәтиҗәләр ясарга, чагыштырырга, группаларга бүлергә;
-2 информация чыганагы белән эшләргә (дәреслек һәм эш дәфтәре): шартлы билгеләрне чагыштырырга, кулланырга;
-алфавит белән эшләргә.

**Коммуникатив УУГ:**

**Укучылар өйрәнә алачак:**

-үзеңнең позициянне башкаларга җиткерергә (язма һәм телдән сөйләмдә фикерне җиткерү);
-башкаларны тыңларга, аңларга;
-дәрестә фикер алышырга, әңгәмәдә катнашырга;
-бергә-бергә бер фикергә килергә;
-биремнәрне парлашып, группада эшләргә .

**Регулятив УУГ:**

**Укучылар өйрәнә алачак:**

-хаталар өстендә эшне эшләргә кирәклеген аңлау;
- хаталар өстендә эшне өлкәннәр ярдәмендә эшләү;
-укытучы ярдәме белән һәм мөстәкыйль рәвештә дәрестә эшчәнлекнең максатын билгеләү;
-укытучы белән берлектә уку проблемасын ачыклау, тәгъбир итү;
-дәрестә практик эшчәнлекне планлаштырырга өйрәнү;
-эш барышында кирәкле чараларны, әйберләрне (рәсем,таблица,карандаш, линейка) куллану;
-укытучы белән диалогта эшеңнең уңышлылыгын билгеләү

**Укучыларның белеменә, эш осталыгына һәм күнекмәләренә таләпләр.**

***Әзерлек чоры ахырына балалар өйрәнәчәк:***

- Элементар образлы күзаллау дәрәҗәсендә тел берәмлекләре: сүз, җөмлә, текстны аңлый, шулай ук татар алфавитының басма һәм язма хәрефләр системасын атый һәм формалары буенча аера белергә;.

- Рәсем, график модель яки тиешле фишкалар кулланып, беренчедән, дәрестә тудырылган тел ситуацияләре буенча 2 — 4 сүздән торган җөмләләр һәм 3 — 4 җөмләдән торган хикәя төзи; икенчедән, парта артында дөрес утыра һәм язма әсбаплардан дөрес файдалана, алгоритм буенча яки тактлап язма хәрефләрнең барлык элементларын да дөрес яза белергә тиешләр.
- Дөрес утыру һәм язу әсбапларын дөрес куллану кагыйдәләре.Дөрес утыру һәм язу әсбапларын дөрес куллану күнекмәләрен камилләштерү.
- Уку дәресләрендә элемент-өлгеләр ярдәмендә басма хәрефләрне төзү күнегүләре. Балалар хәтерендә барлык басма хәрефләрнең күрмә образларын формалаштыру.
- Балалар хәтерендә язма баш һәм юл хәрефләренең төгәл күрмә-хәрәкәтле образларын формалаштыру. Бу хәрефләрне алгоритм һәм тактлап (санап) язу технологиясен камилләштерү.

***Әлифбаны (грамотага өйрәтү) бетергәндә укучылар түбәндәгеләрне белергә тиеш:***

- укырга – язарга өйрәтү барышында гамәли алынган белемнәрне, эш осталыгын һәм күнекмәләрне гомумиләштерү, системалаштыру;
- сүзләрне иҗекләргә бүлү, юлдан юлга күчерү;
- язуга карата төп гигиена кагыйдәләрен үтәү;
- хәрефләрнең график яктан дөрес язылышын, сүздә аларны тоташтыру ысулларын;
- хәрефләрне дөрестоташтырып, ритмлап иҗекләр, сүзләр, кечкенә җөмләләр язу;
- кечкенә текстларны тактадан, дәреслектән дөрес итеп (иҗек һәм хәрефләрне төшереп калдырмый, урыннарын алмаштырмый, хәреф формаларын бозмыйча), сүзләп күчереп язу;
- әйтелеше белән язылышы туры килгән сүзләрдән төзелгән җөмләләрне ишетеп язу (диктант);
- **э,о,ө,й,е,ю,я** хәрефләре, **йө,йо** кушылмалары булган сүзләрне дөрес язу; кеше исем, фамилияләрен, хайван кушаматларын, җөмлә башындагы сүзләрне баш хәрефтән язу;
- җөмлә ахырында нокта кую;
- билгеле бер темага һәм рәсемнәргә карата җөмләләр уйлау;
- сюжетлы рәсемнәр, балаларның күзәтүләре буенча укытучы куйган сораулар ярдәмендә телдән кечкенә хәкәяләр төзү.

***1 классны тәмамлаганда укучылар белергә тиеш:***

- татар телендәге барлык аваз һәм хәрефләрне гамәли танып белергә, аваз белән хәрефнең төп аермасын практик аңлауга ирешергә тиеш;
- сүзләрне авазларга таркату, авазларны сүздәге тәртиптә әйтү;
- сүзык һәм тартык авазларны һәм аларның хәрефләрен аерып таный белү;
- калын һәм нечкә сузыкларны дөрес әйтү;
- сүзләрне иҗекләргә бүлү;
- җөмләләрне сүзләргә таркату;
- баш һәм юл хәрефләрен, аларны тоташтыручы сызыкларны һәм сүзләрне ачык итеп, бозмыйча язу;
- басма, язма хәрефләр белән бирелгән сүз һәм җөмләләрне дөрес күчереп язу;
- әйтелеше белән язылышы туры килгән сүзләрне, шундый сүзләрдән төзелгән 3-5 сүзле җөмләләрне ишетеп дөрес язу;

– җөмләнең беренче сүзен баш хәреф белән башлап, җөмлә беткәч, нокта куеп язу;
– телдән 4-5 җөмләле кечкенә хикәяләр төзү;

**Беренче сыйныф укучыларының белеменә, эш осталыгына һәм күнекмәләренә таләпләр.**

***Төп чор** ахырына балалар өйрәнәчәк*:

1. Татар теленең авазларының сузык (ачык авыз символы белән бирелгән), ягъни җырлана торган аваз һәм тартык, ягъни җырланмый торган; әйткәндә, сөйләм органнарында киртә ясала / ясалмый торган авазларга бүленүен, сузыкларның калын һәм нечкә булуын, тартыкларның нечкә- калын яңгырашын сузык аваз хәрефләре белдерүен;
- сүзнең яңгыраш һәм мәгънә бөтенлегенә ия булуын;
- сүзнең иҗекләргә бүленүен, бер иҗекнең көчлерәк һәм озынрак әйтелүен;
- сөйләм авазлары язуда шартлы график символлар (түгәрәк, квадрат) яки хәрефләр белән белдерелүен;
- сүзләр предметларны, аларның билгеләрен, эш-хәрәкәтләрен белдерүләрен, ярдәмче сүзләр сүзләрне, җөмләләрне үзара бәйләү өчен хезмәт итүләрен, аларның график символларын;
- әйтмә сөйләмнең текст һәм җөмләләргә бүленүен, аларны график сурәтләп булу мөмкинлеген;
элемент-сызыклар һәм элемент-өлгеләрнең басма һәм язма хәрефләрнең график системасының структур (төзелеш) берәмлекләре булуын;
- һәр басма һәм язма хәреф формасының тиешле урын-сан мөнәсәбәтендә урнашкан элементлардан торуын аңлый белергә тиеш.
2. Укучылар сүз башыннан башлап, андагы һәр авазны көчлерәк итеп билгели бара, берсен аерып алып аңа характеристика бирә;
- анализ вакытында тартыкларның яңгырау-саңгыраулыгын билгеләү алымнарын куллана;
- сүзне иҗекләргә бүлә;
- схемалардан сүзнең аваз язылышын иҗекләп һәм орфоэпик дөрес итеп укый;
- схемалардагы һәм «Әлифба» текстларында бирелгән хәреф язуын иҗекләп һәм орфоэпик дөрес итеп укый;
- сүзнең аваз формасын шартлы график формадан хәреф формасына һәм киресенчә үзгәртә;
- элемент-шаблоннар нигезендә басма һәм язма хәрефләрне төзи һәм анализлый;
- аерым график биремне үтәү дәвамында дөрес итеп утыра һәм язма әсбаплардан файдалана ала;
- билгеле бер алгоритм буенча хәрәкәт элементлары нигезендә хәрефләр яза;
- иҗекләрдә һәм сүзләрдә тоташтыруның өч алымын үти;
- тактлап язганда кул чугы мускуллары киеренкелеген йомшарта;
- күчереп язганда һәм диктант вакытларында җөмләләрне һәм үз исемнәрен дөрес яза;
- бизәк-бордюрлар ясый ала белергә тиешләр.

Алгоритм буенча сүзләрдә язма хәрефләрнең һәм аларны тоташтыру сызыкларын язу технологиясен ныгыту.
Тактлап язганда кул чугы мускуллары киеренкелеген йомшару халәте белән чиратлаштыра белү.
Язма һәм басма текстлардан сүз һәм җөмләләрне күчереп язу, әйтеп яздыра торган текстны язу.

Грамотага өйрәтүнең ***әлифбадан соңгы чоры**нда* беренче сыйныф укучылары өйрәнәчәк:

1. Туган телнең сөйләм төзелешен аңлый, аваз, иҗек, сүз, сүзтезмә, җөмлә, текст кебек тел берәмлекләрен образлы күзаллый;
- татар алфавиты басма һәм язма хәрефләренең график системасын;

- һәр хәрефнең элемент формаларын;
- дөрес утыру һәм язма әсбапларны куллану кагыйдәләрен белергә тиеш.
2. Һәр укучы үзенә генә хас темпта басма һәм язма текстларны офоэпик нормаларга туры китереп укый;
- текстның аерым бер өлешләрен сөйли (2 — 3 җөмлә белән) ;
- укылган текст эчтәлеге буенча бирелгән сорауларга җавап бирә;
- тыңланган текстка исем куша;
3. О, ө хәрефләрен беренче иҗектә генә язу;
- әйтмә һәм язма сөйләмне тел берәмлекләренең төзелеше турында беренче сыйныф укучыларында формалашкан күзаллау нигезендә анализлау һәм тиешле символлар белән модельләштерү;
- тыныш билгеләренә игътибар итеп, иҗекләп, орфоэпик, бәйләнешле итеп уку алымнарын куллану;
- хәрефләрне язуда тоташ һәм тиз итеп язу алымнарын тормышка ашыру;
- татар теленең позицион принцибына нигезләнеп, [гъ] [къ] авазларын язуда белдерү турында үзләштергән белем һәм күнекмәләрен уку эшчәнлегендә һәм көндәлек тормышта кулланырга өйрәнергә тиешләр
- сүзләрне авазларга таркату; авазларны сүздәге тәртиптә әйтү; сузык һәм тартык авазларны һәм аларның хәрефләрен аерып таный белү; калын һәм нечкә сузыкларны дөрес әйтү; сузык аваз һәм аларның хәрефләренә карап, калын һәм нечкә әйтелгән сүзләрне тану; сүзләрне иҗекләргә бүлү; җөмләләрне сүзләргә таркату. Баш һәм юл хәрефләрен, аларны оташтыручы сызыкларны һәм сүзләрне ачык итеп, бозмыйча язу. Басма, кулдан язылган хәрефләр белән бирелгән сүз һәм җөмләләрне дөрес күчереп язу. Әйтелеше белән язылышы туры килгән сүзләрне, шундый сүзләрдән төзелгән 3-5 сүзле җөмләләрне ишетеп язу. Җөмләнең беренче сүзен баш хәреф белән башлап, җөмлә беткәч, нокта куеп язу.

*Укучылар өйрәнергә мөмкинлек алачак:*

- телдән 4-5 җөмләле кечкенә хикәяләр төзү. Сыйныфта телдән җыр, шигъри куплетлар, мәзәк, әкият уйлап чыгару.
- төрле методик шартларда: 1) басма яки язма текстны күчереп язганда, 2) хәтер буенча яки 3) укытучы әйтеп яздырган вакытта, үзләштерелгән алгоритмга туры китереп аерым да, җөмлә эчендә дә сүзләрне өзмичә язу күнекмәләрен үзләштерә һәр укучы, шәхси мөмкинчелеген истә тотып, язу темпын арттыра белү кебек эш төрләрен башкара белергә тиеш.
-график хаталарны төзәтү һәм каллиграфик язу сыйфатын камилләштерү эшләре.
-тизләтелгән темпта язу шартларында график грамоталылыкны һәм каллиграфик сыйфатны формалаштыру.

***Программа эчтәлеге***

**Әзерлек чоры – 4 сәгать**

Язганда дөрес утыру һәм язу әсбапларын дөрес куллану кагыйдәләре белән танышу. Дәфтәр битләрендә ориентлашу, андагы сызыклар белән танышу. Вертикаль, горизонталь һәм авыш сызыклар турында белешмә.

Татар алфавиты хәрефләре график системасының структур берәмлеге буларак кулланылган элемент-сызыклар. Алгоритм буенча элемент-сызыкларны язу. Язма хәрефләрнең өлге формалары белән танышу. Бордюр-бизәкләр ясау процессында язма хәреф элементлары турында күзаллау тудыру.

График системаның структур берәмлеге булган язма хәреф элементларын чагыштыру, төркемләү һәм йомгаклау, гомуми нәтиҗә ясауга корылган логик күнегүләр үтәү.

**Әзерлек чоры ахырына балалар**:

1. Элементар образлы күзаллау дәрәҗәсендә тел берәмлекләре: сүз, җөмлә, текстны **аңлый**, шулай ук татар алфавитының басма һәм язма хәрефләр системасын **атый һәм формалары буенча аера белергә**;.
2. Рәсем, график модель яки тиешле фишкалар кулланып, беренчедән, дәрестә тудырылган тел ситуацияләре буенча 2 — 4 сүздән торган **җөмләләр** һәм 3 — 4 җөмләдән торган **хикәя төзи**; икенчедән, парта артында **дөрес утыра** һәм язма әсбаплардан дөрес **файдалана**, алгоритм буенча яки тактлап язма хәрефләрнең барлык элементларын да **дөрес яза белергә тиешләр.**

**Төп чор – 36 сәгать**

Дөрес утыру һәм язу әсбапларын дөрес куллану кагыйдәләре.Дөрес утыру һәм язу әсбапларын дөрес куллану күнекмәләрен камилләштерү.

Уку дәресләрендә элемент-өлгеләр ярдәмендә басма хәрефләрне төзү күнегүләре. Балалар хәтерендә барлык басма хәрефләрнең күрмә образларын формалаштыру.

Язу дәресләрендә элемент-өлгеләрдән язма хәрефләр төзү һәм анализлау. Гомуми уртак элемент формалары буенча хәрефләрне төркемләү һәм чагыштыру буенча логик биремнәр үтәү.

Балалар хәтерендә язма баш һәм юл хәрефләренең төгәл күрмә-хәрәкәтле образларын формалаштыру. Бу хәрефләрне алгоритм һәм тактлап (санап) язу технологиясен камилләштерү.

Язуда оч төрле (өске, урта-йөзмә, аскы) тоташтыру алымы белән танышу.Дәрестә өйрәнелә торган хәрефне элек өйрәнелгән хәрефләр белән тоташтыру алгоритмнарын үзләштерү.

Тактлап язу алымы нигезендә кул чугы мускуллары киеренкелеген йомшарту (киметү) белән ритмик чиратлаштыру күнегүләре.

Сүзнең аваз схемасын график формага үзгәртү һәм алга таба язма хәрефләр белән язу. Язма хәрефләр белән бирелгән иҗек, сүз, җөмлә үрнәкләрен уку. үрнәк буенча язу. укучыларның үз язуларының нәтиҗәләрен тикшерүләре.

**Төп чорның ахырына балалар:**

1. Татар теленең авазларының сузык (ачык авыз символы белән бирелгән), ягъни җырлана торган аваз һәм тартык, ягъни җырланмый торган; әйткәндә, сөйләм органнарында киртә ясала/ясалмый торган авазларга бүленүен, сузыкларның калын һәм нечкә булуын, тартыкларның нечкә- калын яңгырашын сузык аваз хәрефләре белдерүен;

- сүзнең яңгыраш һәм мәгънә бөтенлегенә ия булуын;
- сүзнең иҗекләргә бүленүен, бер иҗекнең көчлерәк һәм озынрак әйтелүен;
- сөйләм авазлары язуда шартлы график символлар (түгәрәк, квадрат) яки хәрефләр белән белдерелүен;

- сүзләр предметларны, аларның билгеләрен, эш-хәрәкәтләрен белдерүләрен, ярдәмче сүзләр сүзләрне, җөмләләрне үзара бәйләү өчен хезмәт итүләрен, аларның график символларын;
- әйтмә сөйләмнең текст һәм җөмләләргә бүленүен, аларны график сурәтләп булу мөмкинлеген;
элемент-сызыклар һәм элемент-өлгеләрнең басма һәм язма хәрефләрнең график системасының структур (төзелеш) берәмлекләре булуын;
- һәр басма һәм язма хәреф формасының тиешле урын-сан мөнәсәбәтендә урнашкан элементлардан торуын **аңлый белергә тиеш.**
2. Укучылар сүз башыннан башлап, андагы һәр авазны көчлерәк итеп **билгели бара**, берсен аерып алып аңа **характеристика бирә**;
- анализ вакытында тартыкларның яңгырау-саңгыраулыгын билгеләү алымнарын **куллана;**
- сүзне иҗекләргә **бүлә**;
- схемалардан сүзнең аваз язылышын иҗекләп һәм орфоэпик **дөрес итеп укый**;
- схемалардагы һәм «Әлифба» текстларында бирелгән хәреф язуын иҗекләп һәм орфоэпик дөрес итеп **укый;**
- сүзнең аваз формасын шартлы график формадан хәреф формасына һәм киресенчә **үзгәртә;**
- элемент-шаблоннар нигезендә басма һәм язма хәрефләрне **төзи һәм анализлый;**
- аерым график биремне үтәү дәвамында дөрес итеп утыра һәм язма әсбаплардан **файдалана ала;**
- билгеле бер алгоритм буенча хәрәкәт элементлары нигезендә хәрефләр **яза;**
- иҗекләрдә һәм сүзләрдә тоташтыруның өч алымын **үти;**
- тактлап язганда кул чугы мускуллары киеренкелеген **йомшарта;**
- күчереп язганда һәм диктант вакытларында җөмләләрне һәм үз исемнәрен **дөрес яза;**
- бизәк-бордюрлар **ясый ала белергә тиешләр**.

**Йомгаклау чоры – 2 сәгать**

Алгоритм буенча сүзләрдә язма хәрефләрнең һәм аларны тоташтыру сызыкларын язу технологиясен ныгыту.

Тактлап язганда кул чугы мускуллары киеренкелеген йомшару халәте белән чиратлаштыра белү.

График хаталарны төзәтү һәм каллиграфик язу сыйфатын камилләштерү эшләре. Тизләтелгән темпта язу шартларында график грамоталылыкны һәм каллиграфик сыйфатны формалаштыру.

Язма һәм басма текстлардан сүз һәм җөмләләрне күчереп язу. әйтеп яздыра торган текстны язу.

**Грамотага өйрәтүнең йомгаклау чорында беренче сыйныф укучылары:**

1. Туган телнең сөйләм төзелешен **аңлый**, аваз, иҗек, сүз, сүзтезмә, җөмлә, текст кебек тел берәмлекләрен образлы **күзаллый**;
- татар алфавиты басма һәм язма **хәрефләренең график системасын**;
- һәр хәрефнең элемент **формаларын;**
- дөрес утыру һәм язма әсбапларны куллану **кагыйдәләрен белергә тиеш.**
2. Һәр укучы үзенә генә хас темпта басма һәм язма текстларны офоэпик нормаларга туры китереп **укый;**
- текстның аерым бер өлешләрен **сөйли** (2 — 3 җөмлә белән) ;
- укылган текст эчтәлеге буенча бирелгән сорауларга **җавап бирә;**

- тыңланган текстка **исем куша**;
- төрле методик шартларда: 1) басма яки язма текстны күчереп язганда, 2) хәтер буенча яки 3) укытучы әйтеп яздырган вакытта, үзләштерелгән алгоритмга туры китереп аерым да, җөмлә эчендә дә сүзләрне өзмичә **язу күнекмәләрен үзләштерә** һәр укучы, шәхси мөмкинчелеген истә тотып, **язу темпын арттыра белү кебек эш төрләрен башкара белергә тиеш**.
3**. О, ө** хәрефләрен беренче иҗектә генә **язу;**
- әйтмә һәм язма сөйләмне тел берәмлекләренең төзелеше турында беренче сыйныф укучыларында формалашкан күзаллау нигезендә **анализлау** һәм тиешле символлар белән **модельләштерү;**
- тыныш билгеләренә игътибар итеп. иҗекләп, орфоэпик, бәйләнешле итеп уку алымнарын **куллану;**
- хәрефләрне язуда тоташ һәм тиз итеп язу алымнарын **тормышка ашыру**;
- татар теленең позицион принцибына нигезләнеп, **[гь] [кь]** авазларын язуда **белдерү** турында **үзләштергән белем һәм күнекмәләрен уку эшчәнлегендә һәм көндәлек тормышта кулланырга өйрәнергә тиешләр.**

**Татар теле**
Аңлатма язуы

Грамотага өйрәнү чорыннан соң Татар теле курсы өйрәнелә. Укучы беренче сыйныфтан башлап, татар телен системалы рәвештә өйрәнә башлый. Бу чорда телдән сөйләмнең башлангыч күнекмәләре үстерлә һәм балада язма сөйләм формалаша башлый. Сөйләм күнекмәләренең үсүе укучының ана телендә фикерләү эшчәнлеген камилләштерүдә хәлиткеч роль уйный.

Тәкъдим ителә торган программада татар теленә өйрәтүнең төп максаты һәм бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбәрәт:

1. Укучыларда ана телен өйрәнүгә кызыксыну, омтылыш, эзләнергә теләк уяту, үз милләтенә, теленә мәхәббәт тәрбияләү кебек уңай сыйфатлар булдыру.
2. Балаларга татар теленең төрле бүлекләре буенча белем бирү:
   - Фонетика, лексика, грамматикага караган башлангыч мәгълүмат бирү;
   - Телебезнең орфоэпиясе, лексикасы, грамматикасы, пунктуаөиясе буенча күнекмәләр булдыра башлау. Хәрефләрдән иҗекләр һәм сүзләр, сүзләрдән сүзтезмәләр һәм җөмләләр төзергә өйрәтү.
3. Укучыларны дөрес һәм матур итеп укырга, укыганның эчтәлеген сөйләргә, аерым темалар буенча әңгәмәләр кора белергә, аралашканда тел чараларыннан урынлы файдаланырга өйрәтү.
4. Телдән һәм язма сөйләм осталыгы һәм күнекмәләре булдыру.
5. Укучыларда татар мәдәниятенә караган мәгълүматлылыкны үстерү.

   Перспектив башлангыч мәктәпнең 1 нче сыйныфында укучылар аваз белән хәрефләрне аерырга өйрәнәләр, сүз басымы, исем, сыйфат, фигыль турында башлангыч мәгълүмат алалар. Балалар сөйләм берәмлеге буларак җөмлә турында төшенчә ала, терминнарны әйтмичә генә, җөмләдәге баш кисәкләрне, өстәмә предметны белдергән сүзләрне һәм ярдәмче сүзләрне табу һәм урынын билгеләү кебек эш төрләренә өйрәнә. Дәресләрдә җөмләләрне төрле тавыш (интонация) белән әйтү, сүзләрдән җөмләләр, җөмләләрдән кечкенә хикәяләр төзи белү күнекмәләре булдырыла.

Сөйләм телен үстерү уку дәресләре белән бергә дәвам иттерелә. Татар теле дәресләрендә халык авыз иҗаты үрнәкләреннән табышмаклар, мәкаль-әйтемнәр, санамышлар ятлау, аларны дәфтәрләргә дөрес һәм матур итеп язып кую да балаларны татарча аңлаешлы, әдәби нормаларга туры килердәй итеп сөйләргә өйрәтүдә зур әһәмияткә ия булып тора.

**Программаның эчтәлеге**
**Татар теле ( 24 сәгать)**

**Алфавит**. Хәрефләрне дөрес итеп уку (әйтү). Алфавиттагы хәрефләрнең урынын белү. Китапларны киштәләргә авторларның фамилияләренең баш хәрефенә карап урнаштыра белү. Сүзлекләр төзүдә алфавитны белүнең әһәмиятен аңлау.

**Авазлар һәм хәрефләр**. Сузык һәм тартык авазлар. Калын һәм нечкә сузыклар, аларны белдерә торган хәрефләрнең дөрес язылышы. Авазларның калынлыкта-нечкәлектә ярашуы.

**Иҗекләрне һәм сүзләрне дөрес уку һәм язу.** Сүзләрне иҗекләргә бүлү, аларны юлдан юлга күчерү. Сүзне тиешле басым белән әйтү (уку).

**Яңгырау һәм саңгырау тартыклар, аларны белдерә торган хәрефләрнең дөрес язылышы**. Парлы һәм парсыз яңгырау һәм саңгырау тартыклар.

**Предмет атамасын белдергән сүзләр – исемнәр белән таныштыру**. Аларның мәгънәләрен аңлату, сорауларын әйтү; уртаклык һәм ялгызлык исемнәр һәм аларның язылышы. Исемнәр янында кулланыла торган ярдәмче сүзләр – бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр белән таныштыру.

**Предметның билгесен белдергән сүзләр белән таныштыру**.

**Эш-хәрәкәтне белдергән сүзләр –фигыльләр белән таныштыру.**

**Телдән һәм язма сөйләм**. Телдән сөйләмнең үзенчәлекләре (интонаөия, сүз басымы). Язма сөйләм үзенчәлекләре (җөмлә башында, ялгызлык исемнәрдә баш хәреф). Аерым сүзләрдән җөмләләр төзү. Төрле интонация белән әйтелгән җөмләләрдән соң куелган тыныш билгеләре.

**Әзер тексттан сүз, сүзтезмә һәм җөмләләрне дөрес итеп күчереп язу**. Аннан соң аларны укытучы әйтүе буенча язу, ул тәкъдим иткән сүзләрдән сүзтезмә һәм җөмләләр төзү.

Аерым темалар буенча өйрәнгән сүзләрне, сүзтезмә һәм җөмләләрне диктант итеп язу. Матур язу күнегүләрен үтәү. Сөйләм күнекмәләре булдыру өстендә даими эшләү.

**Бәйләнешле сөйләм үстерү**

Иҗекләрдән сүзләр, сүзләрдән сүзтезмәләр һәм җөмләләр төзү. Терәк сүзләр ярдәмендә җөмләләр төзү.

Аерым темалардагы сүзләр белән сүзтезмәләр һәм җөмләләр төзү, сорауларга җавап бирү, 3-4 җөмләдән торган бәйләнешле сөйләм оештыру.

Рәсемнәргә карап, сораулар бирү һәм аларга җавап кайтару, рәсем буенча кечкенә хикәяләр төзергә өйрәнү.

Шигырь, мәкаль, әйтем һәм табышмаклар ятлау.

Татар сөйләм әдәбенә хас булган сүзләрне дөрес куллану (танышканда, саубуллашканда, табын артында утырганда, рәхмәт әйткәндә, мөрәҗәгать иткәндә, гафу үтенгәндә, тәбрикләгәндә һ..б. очракларда).

**Татар теленнән укучыларның белем дәрәҗәләрендә көтелгән нәтиҗәләр**

- Аваз һәм хәрефләрне танып белү, аларның аермасын аңлатып бирү (аваны әйтәбез, ишетәбез, сүзләр авазлардан тора тора; хәрефне күрәбез, таныйбыз, язабыз, укыганда шул хәрефнең авазын әйтәбез)
- Сүзләрнең мәгънәсен аеруда авазларның әһәмиятен гамәли аңлау
- Авазларны сузык һәм тартыкларга аеру, аларны сүздән тыш та ачык һәм дөрес әйтү; тартык һәм сузык авазлар арасындагы аермалык нигезен аңлау һәм шуны аңлату; калын һәм нечкә сузыкларның үзлеген белү, укыганда, сүзләрнең калын һәм нечкә әйтелешен сайлау өчен, шул үзлектән файдалану
- Татар алфавитын яттан белү, алфавитның әһәмиятен аңлау һәм аңлату
- Баш һәм юл хәрефләрен, аларны тоташтыручы сызыкларны аермачык, бозмыйча язу; сүзләрне матур, дөрес, хәрефләрне төшереп калдырмыйча, өстәмичә, урыннарын алыштырмыйча язу
- Сүзләрне иҗекләргә бүлү, авазларга таркату, иҗек санын сузык авазларга мөнәсәбәтле итеп билгеләү; сүз басымын ишшетеп билгеләү
- Предмет, эш – хәрәкәт, билге атамалары булган сүзләрне сораулар куеп аера, төркемләштерә белү, аларның сөйләмдәге ролен гамәли аңлау
- Җөмләне сүздән, сүзтезмәдән аера белү, язганда, җөмләнең башын һәм азагын дөрес күрсәтү
- Әйтелеше белән язылышы туры килгән 3 – 5 сүзле җөмләне ишетеп язу
- Беренче сыйныфта өйрәнгән күләмдә авазларга характеристика бирү
- Сүзне, җөмләне, текстны схема яки модель итеп күрсәтә белү
- Укытучы һәм сыйныфташлар белән кара – каршы әдәпле сөйләшү
- Балаларның яшь үзенчәлекләренә туры килгән табышмакларның җавабын табу, кыска мәкаль – әйтемнәрне сөйләмдә куллану.

**Татар теленнән укучыларның белем дәрәҗәсенә таләпләр**

- Татар алфавитын белү
- Татар теленең авазларын һәм хәрефләрен, аларның әйтелеш, язылыш үзенчәлекләрен аңлау һәм рус теле белән чагыштыру
- Сүзләрне иҗекләргә бүлү, сүз басымын билгеләү
- Сүзтезмә һәм җөмләне аеру, җөмләнең әйтү максаты буенча төрләрен аеру
- Авазларга характеристика бирү

**Татар теленнән формалашырга тиешле күнекмәләр**

- Бирелгән җөмләләрне аңлап һәм дөрес итеп укый белү
- Текстны дөрес итеп күчереп язу

- Укылган (тыңланган) текстка карата сораулар куя белү, текст эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирә алу
- Зур булмаган текстның эчтәлеген сөйләү
- Диалогик һәм монологик формада аралашу күнекмәләренә ия булу
- Көндәлек аралашуга бәйле татар сөйләм этикеты формаларын дөрес куллану

**Татар теленнән предметара эшчәнлек**

- Тел материалын уку материалы белән бәйләп, татар теленең байлыгына һәм матурлыгына хөрмәт тәрбияләү
- Татар һәм рус телләренең уртак һәм аермалы якларын күрә белү, сөйләм барышында ике тел чараларын бутамау
- Татар теленә рус теленнән һәм рус теле аша башка телләрдән кергән лексик чараларны аеруга игтибар юнәлтү
- Татар теленнән алган белемнәрне башка фәннәрне үзләштерүдә куллана белү

**Татар теленнән шәхси үсеш – үзгәреш**

- Баланың физик һәм психик сәламәтлеген саклау
- Укучыларда татар телен өйрәнүгә кызыксыну, омтылыш уяту
- Тел аша әйләнә – тирә тормышка игтибар, дөрес мөнәсәбәт булдыру
- Укучыларның фикерләү сәләтен үстерү
- Баланың үзенә һәм башкаларга бәя бирүен, үз – үзен тәрбияләвенә ирешү

**Календарь -тематик  планлаштыру.**

| № п/п | Дәрес темасы | Эшчәнлек төрләре | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|
| | | | план | факт |
| | ӘЗЕРЛЕК ЧОРЫ (4 сәг.) | | | |
| 1. | Язу юлы белән танышу.<br>Җөмлә, сүз схемаларын сызу. | Сүз турында төшенчә бирү, бәйләнешле сөйләм телен үстерү, сүз схемаларын сызарга өйрәтү | 04.09 | 04.09 |
| 2. | Иҗек схемасын сызу.<br>Предмет рәсемнәрен ясау. | График схемалар ярдәмендә сүзләрне иҗекләргә бүлергә өйрәтү | 06.09 | 06.09 |
| 3. | Овал һәм ярымоваллардан торган хәреф элементлары язу. | Сүз турында төшенчә бирү, бәйләнешле сөйләм телен үстерү,овал һәм ярымоваллардан торган хәреф элементлары язуны өйрәтү, хезмәт тәрбиясе бирү | 11.09 | 11.09 |
| 4. | Озын туры сызык, астан элмәкле туры сызыклар һәм аларны тоташтыру | Сүз турында төшенчә бирү, бәйләнешле сөйләм телен үстерү,<br>Озын һәм туры сызык, астан элмәкле туры сызык язарга ,аларны тоташтырырга өйрәтү, хезмәт тәрбиясе бирү | 13.09 | 13.09 |
| | ***ӘЛИФБА ЧОРЫ*** (36 сәг.) | | | |
| 5. | А,а   хәрефләрен язу. | А, а хәрефе белән таныштыру, бәйләнешле сөйләм телен үстерү; А,а хәрефен язарга өйрәтү | 18.09 | 18.09 |
| 6 | Ә,ә хәрефләрен язу | Ә, ә  хәрефе белән таныштыру, бәйләнешле сөйләм телен үстерү; А,а хәрефен язарга өйрәтү | 20.09 | 20.09 |
| 7. | Сузык [ы] авазы һәм ы,Ы .  [э]авазы  Э,э(е) хәрефләре. | Иҗек турында төшенчә бирү, бәйләнешле сөйләм телен үстерү, А ,а, Ә, ә Ы,ы хәрефләрен язуны ныгыту,көзге табигатькә мәхәббәт тәрбияләү | 25.09 | |
| 8 | Сузык  [и] авазы<br>И,и  хәрефләре. | И,и аваз,хәрефе белән таныштыру, бәйләнешле сөйләм телен үстерү;И,и хәрефен язарга өйрәтү | 27.09 | |
| 9 | У, у, Ү,ү   хәрефләрен язу. | У.у Ү,ү  хәрефләре белән таныштыру, бәйләнешле сөйләм телен үстерү; У,у ,Ү,ү хәрефләрен язарга өйрәтү | 2.10 | |
| 10. | Сузык [о,] авазы һәм о,О хәрефләре. | О,о  хәрефләрен язарга өйрәтү, әдәби китаплар белән таныштыру, бәйләнешле сөйләм телен үстерү | 04.10 | |
| 11. | Сузык [ө] авазы һәм ө,Ө хәрефләре. | Ө,ө хәрефен язарга өйрәтү | 09.10 | |
| 12. | Тартык,яңгырау  [н] авазы . н,Н хәрефләре. | Баш Н, юл нхәрефен  язарга өйрәтү, әйтеп ишетеп язу күнекмәләрен | 11.10 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | ныгыту кушылмалар язу<br>На,нә,ни, ну, нү,но,нө | | |
| 13 | Тартык,яңгырау [л] авазы , л,Л хәрефләре. | Л,л хәрефен язарга өйрәтү\кушылмалар язу | 16.10 | |
| 14 | Тартык, яңгырау [м]авазы, м,М хәрефләре. | Юл м һәм баш М хәрефен язарга өйрәтү | 18.10 | |
| 15 | Тартык, яңгырау [р] авазы ,<br>Р ,р хәрефләре. | Баш Р, юл рхәрефен язарга өйрәтү, әйтеп ишетеп язу күнекмәләрен ныгыту | 23.10 | |
| 16 | Тартык, яңгырау [й] авазы һәм Й, й хәрефе. | Й,й хәрефен язарга өйрәтү, әйтеп ишетеп язу күнекмәләрен ныгыту | 25.10 | |
| | | **2нче чирек** | | |
| 17 | Яңгырау, тартык [ң] авазы һәм ң хәрефе. | Ң хәрефен язарга өйрәтү, әйтеп ишетеп язу күнекмәләрен ныгыту | 6.11 | |
| 18 | Сузык Я,я хәрефләре. | Я хәрефен язарга өйрәтү, әйтеп ишетеп язу күнекмәләрен ныгыту (йа) (йә) | 8.11 | |
| 19 | Сузык Ю,ю хәрефләрен язу. | Ю хәрефен язарга өйрәтү, әйтеп ишетеп язу күнекмәләрен ныгыту (йу) (йү) | 13.11 | |
| 20 | Сузык Е е хәрефенең [йы] [йэ] авазын белдерүе. | Е,е хәрефен язарга өйрәтү, әйтеп ишетеп язу күнекмәләрен ныгыту (йы) (йэ) | 15.11 | |
| 21 | Яңгырау тартык [д] авазы<br>һәм Д , д хәрефләре. | Д,д хәрефен язарга өйрәтү, әйтеп ишетеп язу күнекмәләрен ныгыту | 20.11 | |
| 22. | Саңгырау тартык [т] авазы,<br>Һәм Т,т хәрефләре. | Т,т хәрефен , иҗекләр, сүзләр язарга өйрәтү, әйтеп ишетеп язу күнекмәләрен ныгыту | 22.11 | |
| 23. | Яңгырау тартык [з] авазы һәм З,з хәрефләрен язу. | З,з хәрефен , иҗекләр, сүзләр язарга уйрәтү, әйтеп ишетеп язу күнекмәләрен ныгыту | 27.11 | |
| 24 | Саңгырау тартык [с]авазы һәм С,с хәрефләре. | С,с хәрефен , иҗекләр, сүзләр язарга өйрәтү, әйтеп ишетеп язу күнекмәләрен ныгыту | 29.11 | |
| 25. | Яңгырау тартык [гъ],[г] авазлары. Г,г хәрефе | Г.г хәрефен , иҗекләр, сүзләр язарга өйрәтү, әйтеп ишетеп язу күнекмәләрен ныгыту | 4.12 | |
| 26 | Саңгырау тартык [къ],[к] авазлары,К,к хәрефләре. | К,к хәрефен , иҗекләр, сүзләр язарга өйрәтү, әйтеп ишетеп язу күнекмәләрен ныгыту | 06.12 | |
| 27. | Ирен-ирен [w] һәм ирен-ирен [в] авазлары һәм В,в хәрефләре | В ,в хәрефен , иҗекләр, сүзләр язарга өйрәтү, әйтеп ишетеп язу күнекмәләрен ныгыту | 11.12 | |
| 28. | Саңгырау тартык [ф] авазы һәм Ф, ф | Ф,ф хәрефен , иҗекләр, сүзләр язарга өйрәтү, әйтеп ишетеп язу | 13.12 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | хәрефләре | күнекмәләрен ныгыту | | |
| 29. | Яңгырау тартык [б] авазы<br>һәм Б,б хәрефләре. | Б,б хәрефен , иҗекләр, сүзләр язарга өйрәтү, әйтеп ишетеп язу күнекмәләрен ныгыту | 18.12 | |
| 30. | Саңгырау тартык [п] авазы,<br>П ,п хәрефләре | П,п хәрефләре, аларның аваз мәгънәләре белән таныштыру, сүзләр укырга өйрәтү, бәйләнешле сөйләм телен үстерү, | 20.12 | |
| | | **3нче чирек** | | |
| 31 | Яңгырау тартык [ж] авазы һәм Ж, ж хәрефләре. | Җ хәрефләрен язу | 8.01 | |
| 32. | Саңгырау тартык [ш] авазы, Ш , ш хәрефләре. | Әйтеп ишетеп язу күнекмәләрен ныгыту, грамоталы язу күнекмәләре булдыру | 10.01 | |
| 33. | Яңгырау тартык [җ] авазы һәм җ,Җ хәрефләре. | Җ хәрефен , сүзләр язарга өйрәтү, әйтеп ишетеп язу күнекмәләрен ныгыту, грамоталы язу күнекмәләре булдыра башлау | 15.01 | |
| 34 | Саңгырау тартык [ч] авазы,<br>Ч ,ч хәрефләре. | Ч,ч хәрефен , сүзләр язарга өйрәтү, әйтеп ишетеп язу күнекмәләрен ныгыту, грамоталы язу күнекмәләре булдыра башлау | 17.01 | |
| 35 | Саңгырау тартык [х] авазы,<br>Х,х хәрефләре. | Хх хәрефен , сүзләр язарга өйрәтү, әйтеп ишетеп язу күнекмәләрен ныгыту, грамоталы язу күнекмәләре булдыра башлау | 22.01 | |
| 36 | Саңгырау тартык [һ] авазы,<br>һ,Һ хәрефләре. | Һ хәрефен , сүзләр язарга өйрәтү, әйтеп ишетеп язу күнекмәләрен ныгыту, грамоталы язу күнекмәләре булдыра башлау | 24.01 | |
| 37 | Сузык [йо] авазы, Ё, ё хәрефләре | Сүзләр язарга өйрәтү, әйтеп ишетеп язу күнекмәләрен ныгыту, грамоталы язу күнекмәләре булдыра башлау | 29.01 | |
| 38 | Саңгырау тартык [щ] авазы һәм Щ,щ хәрефләре. | Щ хәрефен , сүзләр язарга өйрәтү, әйтеп ишетеп язу күнекмәләрен ныгыту, грамоталы язу күнекмәләре булдыра башлау | 31.01 | |
| 39 | Саңгырау тартык [ц] авазы, Ц, ц хәрефләре. | Ц,ц хәрефләрен язарга өйрәтү | 5.02 | |
| 40 | Ь , ъ хәрефләре булган сүзләр язу. | Ь ,ъ хәрефләре белән таныштыру, сүзләр укырга өйрәтү. Ь,Ъ хәрефләрен язарга өйрәтү | 07.02 | |
| 41 | Бирелгән сүзләрдән җөмләләр төзеп язу. Басмачадан күчерү. | Йөгерек уку күнекмәләрен ныгыту; язуны ныгыту | 12.02 | |
| 42 | Алфавит язу. | Дөрес каллиграфия өстендә эш | 14.02 | |
| 43 | Китаплар ярдәм көтә.Алфавит. | Дөрес каллиграфия өстендә эш. Күнекмәләр эшләү. | 26.02 | |
| 44 | Җөмлә.Җөмлә ахырында тыныш билгеләре. | Җөмлә турында белгәннәрне ныгыту.Модельләштерү.Тыныш билгесен куярга өйрәнү.Җөмлә башын аеру. | 28.02 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| 45 | Балалар сүзләр белән таныша. Сүз төркемнәре. Предметны белдергән сүзләр. | Мәгънәләре буенча сүзләрне төркемләргә бүлү | 5.03 | |
| 46 | Балалар сүзләр белән таныша. Сүз төркемнәре. Эш-хәрәкәтне белдергән сүзләр | Мәгънәләре буенча сүзләрне төркемләргә бүлү | 07.03 | |
| 47 | Балалар сүзләр белән таныша. Сүз төркемнәре. Билгене белдергән сүзләр | Мәгънәләре буенча сүзләрне төркемләргә бүлү | 12.03 | |
| 48 | Ярдәмче сүзләр. | Ярдәмче сүзләрне аерырга, дөрес кулланырга өйрәтү. | 14.03 | |
| 49 | Язма һәм телдән сөйләм серлре | Әйтү максаты буенча җөмләләрнең төрле булуын төшендерү. | 19.03 | |
| 50 | Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр. | Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр турында төшенчә бирү. | 21.03 | |
| | | **4нче чирек** | | |
| 51 | Сузык аваз хәрефләре.<br>Сүзләрне юлдан юлга күчерү. | Сузык аваз хәрефләре,калын һәм нечкә сузыклар белән танышу.<br>Сүзләрне юлдан юлга күчерхү серләре белән танышу. | 4.04 | |
| 52 | Тартык аваз хәрефләре. | Тартык аваз хәрефләре- яңгырау һәм саңгырау тартык ларны аера белергә өйрәтү. | 09.04 | |
| 53 | Э-е хәрефләре | Сүз башында һәм сүз уртасында э-е хәрефләренең язылышы белән танышу. | 11.04 | |
| 54 | Ө-е хәрефләре | Сүз башында Ө һәм сүз уртасында е хәрефләренең язылышы белән танышу. | 16.04 | |
| 55 | О-ы хәрефләре | Сүз башында һәм сүз уртасында о-ы хәрефләренең язылышы белән танышу. | 18.04 | |
| 56 | Я,я хәрефләре | Ике авазга билге буларак Я,ю,е хәрефләренең дөрес язылышы белән танышу. | 23.04 | |
| 57 | Ю,ю хәрефләре | Ике авазга билге буларак Я,ю,е хәрефләренең дөрес язылышы белән танышу. | 25.04 | |
| 58 | Е,е хәрефләре | Ике авазга билге буларак Я,ю,е хәрефләренең дөрес язылышы белән танышу. | 30.04 | |
| 59 | Й хәрефе | Й хәрефенең сүз башында, сүз уртасында язылышы белән танышу. | 2.05 | |
| 60 | В хәрефе. | В ,К-г хәрефе кергән сүзләрне дөрес язу күнекмәләре белән танышу | 7.05 | |
| 61 | К-Г хәрефләре | В ,К-г хәрефе кергән сүзләрне дөрес язу күнекмәләре белән танышу | 09.05 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 62 | Ныгыту. М.н.ң.хәрефләре. | Борын аваз тартыклары кергән сүзләрне язу кагыйдәләре | 14.05 | |
| 63 | "Җөмлә" темасы буенча еллык контроль диктант. | Ел буе өйрәнгәннәрне тикшерү, бәяләү. | 16.05 | |
| 64 | "Авазлар, хәрефләр" темасын кабатлау. | Калын, нечкә сузыклар, яңгырау, саңгырау тартык авазлар турында өйрәнгәннәрне кабатлау, ныгыту | 21.05 | |
| 65 | "Сүз төркемнәре" темасын кабатлау. | Предметны, предметның билгесен, эш-хәрәкәтен белдерүче сүзләр турында белемнәрне кабатлау, ныгыту. | 23.05 | |
| 66 | Уен-дәрес "Кызыклы грамматика" | Ел буе өйрәнгәннәрне кабатлау | 25.05 | |

.

## Әдәбият

**Укучылар өчен әдәбият:**

- Ф.Ш.Гарифуллина, И.Х.Мияссарова, Р.Р.Шәмсетдинова.Әлифба. 1 нче сыйныф: Дәреслек.- Казан: «Мәгариф-вакыт"нәшрияты, 2011.

-И.Х.Мияссарова,Ч.М.Харисова. Татар теле. 1 нче сыйныф: Дәреслек .-Казан «Мәгариф-вакыт"нәшрияты, 2011 .

**Укытучы өчен әдәбият:**

- Ф.Ш.Гарифуллина, И.Х.Мияссарова, Р.Р.Шәмсетдинова.Әлифба. 1 нче сыйныф: Дәреслек.- Казан: «Мәгариф-вакыт"нәшрияты, 2011.

- Р.Г.Вәлитова, С.Г.Вагыйзов. Әлифба . Укытучылар өчен методик кулланма. -Казан «Мәгариф-вакыт"нәшрияты, 2011

-И.Х.Мияссарова,Ч.М.Харисова. Татар теле. 1 нче сыйныф: Дәреслек .-Казан «Мәгариф-вакыт"нәшрияты, 2011 .

-И.Х.Мияссарова,Ч.М.Харисова. Татар теле. 1 нче сыйныф: Методик кулланма.-Казан «Мәгариф-вакыт"нәшрияты, 2011

-С. Г. Вагыйзов "Кызыклы грамматика" ( Казан "Мәгариф" 2012)

**Интернет – ресурслар**

татар электрон библиотекасы http://kitap.net.ru/;

татар телендә интернет белем үзәге http://belem.ru//;

балалар өчен сайт http://balarf.ru/.

https://edu.tatar.ru/el_books- әлифба